# КӨЗ ТУРЫНДА ШИГЫРЬЛӘР

Төзеде Мостафина Ләйсән
Тимергали кызы

# Көз (Әхмәт Ерикәй)

(

- Көз килде. Үләннәр
  Саргайды, шиңде.
  Сап-сары яфраклар
  Җиргә сибелде.

# Кошлар киткәндә
# (*Бари Рәхмәт*)

- — Сыерчыгым, нигә китәсең?
  Сагынырмын сине, киткәчтен.
  — Көз җитте бит инде, мин туңам,
  Килгән идем җәйге костюмнан.

# Яфрак бәйрәме (*Ләбиб Лерон*)

- Яңгыр түгел, кар да түгел,
Яфраклар ява җиргә.
Күз турында җырлыймын мин —
Кушыл син яңа җырга.
Сары, сары, сап-сары
Агачның яфраклары.
Җил исә, ява яфрак —
Көзнең матур чаклары.
Оча яфрак, уйный яфрак
Һаваларда әйләнеп.
Бүген, бүген, бүген, бүген
Яфракларның бәйрәме!

# Көзге җил (Мәрзия Фәйзуллина)

- Көзге җил «усал»,
  Салкын булса да,
  Колак-борыннар
  Бераз туңса да.
  Куркытмый безне
  Һичбер суык җил.

# Көзге яңгыр (*Мәрзия Фәйзуллина*)

- — Апа, безгә артыбыздан
  Шыбыр-шыбыр кем дәшә?
  — Кем дә дәшми, көзге
  яңгыр
  Зонтик белән сөйләшә.

# Көз җитте (Муса Җәлил)

- Киң болыннарда,
  Урман-кырларда,
  Агачлар, гөлләр,
  Күрәмсез,
  Кибеп сулдылар.
- Уйсу җирләрдә,
  Елга, күлләрдә,
  Көзге салкыннан,
  Күрәмсез,
  Сулар туңдылар.

- Көннәр суынды,
  Чишмәләр тынды,
  Безне калдырып,
  Сизәмсез,
  Кошлар да китте.
- Кошлар шикелле
  Бергә гөр килеп,
  Мәктәптә укыр,
  Беләмсез,
  Вакытлар җитте.

# Салкын, саф һава
# ( *Әминә Бикчәнтәева)*

- Салкын, саф
  һава,
  Йомшак кар ява.
  Урамга чыксаң,
  Битләр кызара.
  Кар бөртекләре
  Өстеңә куна,
  Үзләре матур
  Һәм салкын була.

# Күз (Габдулла Тукай)

- Күрәмсез, дустларым, көз килде тышта;
  Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.
- Китә башлады бездән инде кошлар;
  Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.

# Бу кайчак була?
# *(Габдулла Тукай)*

- Кырлар буш кала,
  Яңгырлар ява;
  Җирләр дымлана,
  — Бу кайчак була?

# БЫЕЛ
# (Хәйдәр Гайнетдинов)

- …Көзге урман көлә яна-яна!
  Уйламый да җирдә салкын барын.
  Хәтерләми бугай аланнары
  ап-ак көртләр күмеп киткән чагын…